## *Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге советының XXVII чакырылыш IV утырышы*

**КАРАР**

*исх.№ 50* *Тат.Буләр авылы* *17 октябрь 2022 ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 августындагы 48 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 августындагы 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең даими һәм вакытлы комиссияләре эшендә депутатның катнашуы»;

1.2. 9 статьяның 3 өлешен киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге йөкләмәне үтәү нәтиҗәләре турында депутат Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Советына яисә аның комиссиясенә хәбәр итә.»;

1.3. 10 статьяның 3 өлешендәге икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.4. 3 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.5. 17 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында гамәлдәге законнар нигезендә белешмәләр тапшырырга.»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Исәнсеф авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов